




№67
ноябрь,
2021 ел

**Яр Чаллы шәһәренең “52 нче урта белем бирү мәктәбе” газетасы**




Һәрберебезгә мәгълүм булганча, октябрь аенда ике олы бәйрәм бар. 1991 елдан бирле беренче октябрьдә өлкәннәр көне билгеләп үтелә һәм 5 октябрь укытучылар көне.

Өлкән кешеләр – безнең әти-әниләребез, әби-бабайларыбыз, хезмәт юлын лаеклы узган ветераннарыбыз .Өлкән буын ветераннарыбыз- авырлыклар күргән, дөньяның ачысын-төчесен татыган кешеләр.

Әнидән кала бу дөньяда безнең өчен иң кадерле кешеләр алар безнең әби-бабаларыбыз.

Аларның безнең кебек, шатлыклы балачагы булмаган. Аны сугыш тартып алган, ачлык-ялангачлык, ә инде сугыштан соң хәерчелек.

Бүген дә алар безгә җылы оекбашлар, бияләйләр бәйләп, тәмле ашлар пешерәләр, матур гөлләр үстерәләр, үзләренең киңәшләре белән безгә һәрчак ярдәм итеп торалар.

Бөтен кешелек дөньясына ямь бирүче, елмаюларыгыз белән безне иркәләүче, җылы карашларыгыз белән назлаучы, акыллы фикерләрегез белән безгә ак юл күрсәтүче сөекле әбиләребез,бабайларыз хөрмәтле өлкән укытучыларыбыз, сезне шушы олуг бәйрәм белән чын күңелдән котлыйбыз.


Гомерләре буе хезмәттә кайнаган, сугыш һәм сугыштан соңгы авырлыкларны иңнәрендә күтәргән әби-бабаларыбыз картлык көннәрендә зур игътибарга, хөрмәткә лаек.

Безнең мәктәп укучылары да өлкәннәргә хөрмәт йөзеннән бистәбездә яшәүче өлкән яштәге ветераннар белән очрашты. Аларның өйләренә барып хәлләрен белеп, якыннан танышып, өлкәннәр көне белән котлап кайттылар .





**Өлкәннәрне котладык**







5октябрь көнне укытучылар көне уңаеннан 52нче мәктәптә эшләп лаеклы ялга киткән укытучылар өчен бәйрәм оештырылды.

Башта мәктәп директоры **Дамир Денислам улы Нуриәхмәтов** укытучылар коллективын, килгән кунакларны бәйрәм белән котлады.

“Хөрмәтле өлкәннәребез! Сез безнең мәктәбебездә бер-берегезгә иңне иңгә куеп, лаеклы ялга кадәр намуслы хезмәт иткәнсез, район, республика күләмендә мәктәбебезне танытуга үзегездән зур өлеш керткәнсез. Рәхмәт сезгә, хезмәтләрегез, кылган изгелекләрегез өчен. Без, яшьләр, сезнең киңәшләрегездән тайпылмабыз, үрнәк булырга тырышырбыз.

Сезне бәйрәмебез уңаеннан кайнар котлыйбыз. Сезгә саулык, сәламәтлек, шатлык-куанычлар, олыгайган көнегездә тыныч тормыш телибез”.

Укытучы – дөньяны танып-белергә омтылучы балаларның керсез, пакь күңелләренә гыйлем орлыклары чәчүче һәм аларның тигез матур шытымнар бирүен сабыр гына көтүче Остаз, газизләрдән-газиз әниләр белән бер үк дәрәҗәгә куярлык изге зат. Шулай ук балаларның нечкә саф күңеленә саклык белән генә кагылучы, аларга хаклык энҗеләрен тезүче оста киңәшче, психолог та, уку барышында юл күрсәтүче маяк та, алай гына түгел, укытучы ул – ил-көндә барган һәр яңарыш, һәр борылыш, һәр үзгәрешне үз аңы аша үткәреп, алгарыш мәйданында җиңү яулашкан каһарман шәхес тә!



## Күңелле мизгелләр.

Укытучылар коллективы табигать кочагында.



*Укытучыма.*

**Баласыдай якын күрә**
**Укучының һәрберсен.**
**Йөрәге аша кичереп,**
**Аңлата ул дәресен.**
**Укытучы кояш кебек**
**Тора һәрчак елмаеп.**
**Укытучы булган өчен**
**Аңа һәйкәл куярлык.**
**Ача безгә бу дөньяның**
**Бик күп яңа серләрен.**
**Гел тыңлыйсы килеп тора**
**Аның матур сүзләрен.**

*Хөрмәтле укытучылар, педагоглар!*
*Сезне һөнәри бәйрәмегез, укытучылар көне белән чын күңелдән тәбрик итәбез.*
*Әлеге бәйрәм сезгә бары тик шатлык хисе китерсен.*
*Сезгә ныклы сәламәтлек, гаилә бәхете, иминлек, иҗат һәм һөнәр уңышлары телибез.*





# Халыкара мәктәп китапханәләре айлыгы

Октябрь - Халыкара мәктәп китапханәләр айлыгы уңаеннан мәктәп күләмендә төрле чаралар уздырылды.

Сыйныфлар да **газета журналларга язылу** оештырылды. Кайбер сыйныфлар **«Китапка яңа тормыш”** акциясендә дә актив катнашып китапханә фондын әдәби китаплар белән баеттылар.

Китапханәләр айлыгында активлык күрсәтеп 1г сыныф җитәкчесе Закиева Гөлнара Флүс кызы, 2г сыйныф укучылары Гимазетдинов Артур белән Тимурның,3а сыйныф укучысы Амиров Инсафның әниләре Республикакүләм “**Китап укучы әни”** конкурсында видеоролик ясап катнаштылар.





1г сыйныфында **“Татар халкының милли йолалары”, “Борынгы китаплар тарихы**” кебек китапханә дәресләре узды.



Мәктәпнең беренче катында **“Милли проект “Экология”-балалар карашы”** дигән Республикакүләм балалар рәсемнәреннән конкурс нәтиҗәләренең күчмә күргәзмәсе оештырылды.



2 нче в сыйныф укучылары яраткан әкият геройларына карата үзара рәсем бәйгесе оештырдылар

Сафиуллин Айдар Марат улы җитәкчелегендәге “техник иҗат” түгәрәге укучылары Сафина Д, МухутдиноваА. “**Җилкәнле көймә”** бәйгесендә 3нче урынны яулап кайттылар







**“Текә борычлар”** Тапкырлар һәм шаяннар(КВН) командасы шәһәркүләм ярышта 1нче урынны алып кайттылар.



ЮХИДИ ның пропаганда бүлеге инспекторы Кашапова В.М. башлангыч сыйныф укучылары белән юлда йөрү кагыйдәләре турында әңгәмә уздырды.

3б сыйныф укучылары “**юлда йөрү кагыйдәләре**” нә багышланган сыйныф сәгатендә мәктәп китапханәсе оештырган “юлда йөрү кагыйдәләре “күргәзмәсе белән дә таныштылар.



Укытучылары Закирова Регина Азат кызы җаваплылыгында 5в сыйныф укучылары **“Әкият сөйлим тыңла”** дигән темага проект эше якладылар

# Укытучылар, укучылар, әти-әниләр иҗаты

## Алтын көз



Моңсу гына килде көз ае,
Бар табигать тагын үзгәрде
Кичә яшел,хәтфә болыннар
Алтын төсле шәлгә төренде.

Алтын көзне мактый-мактый,
Салкын җилләр истеләр.
Моңсуланып,каңгылдашып
Җылы якка кошлар киттеләр.

Нинди генә көяз булсаң да
Яратабыз син –көз аен
Уңышларың белән сөендереп
Каршы алсак иде ел саен.

**Нургалиева Эльмира Фәнис кызы.**

## Минем гаиләм



Минем гаиләм бик зур-.
Санарга җитми бер кул.
Әби,бабай,әти,әни,
Сеңелем,энем һәм дә мин.

Без бик тату гаилә!
Гел елмаясы килә.
Гаиләбездә җидәү без,
Матур итеп яшибез!

**Ралина Садриева**
**4а сыйныфы укучысы**

## “Әтәч нигә кычкыра”.

**Зифа Әмирова сүзләре.**

Беләсегез киләме -
Әтәч нигә кычкыра?
Әтәчсез булган иртәләр
Ниләр безгә китерә?
Иртән иртүк “Кик-ри-күк ”дип,
Уята безне әтәч.
Төшемне күреп бетерәалмыйм,
Шулай тавыш күтәргәч.
Тәмам туйгач Чукмардан,
Илтеп куйдым Дамирга.
Дустым белми шул әле
Ниләр көтә аны да.
Тәмләп йоклап ятамын,
Рәхәт, тынлык,бер кем юк.
Тәмле төшләр күреп ятам,
Башкаларда эшем юк.
Төшләремә ни кергәнен
Сөйләп бирәмен сезгә.
Мине аңларсыз әле,
Дамир гына борчый ла
Урман буйлап җиләк җыйдым
Су буенда кызындым.
Чумдым, йөздем, кызык булды,



Чү! Алтын тарак таптым.
Әкияттәге сыман мин
Әй йөгердем, тырыштым.
Шул вакытта үзем көтәм,
Ник кычкырмый
Чукмарым!
Уятыр иде ул мине
Иң кызыклы урында
Уята хәзер Дамирны
Нигә кирәк мин аңа?
Мәктәпкә соңга калдым,
Оекбашлар югалды
Битләремне юарга,
Хәтта вакыт калмады.
Ә дустым Дамир килгән,
Беренчеләрдән булып,
Йөзендә нурлар балкый,
Мыскыллап миннән көлеп.
Кич белән өйгә кайткач,
Алып кайтам Чукмарны.
Белдем инде хәзер дуслар,
Әтәч ник кычкырганны!



Редактор Руслан Логинов
Җаваплы сәркатип Камилә Валиахметова
Корректор Сабирзянова Сабина
Координатор Илфания Нурутдинова

**Безнең адрес: 423827,**
**Яр Чаллы шәһәре,**
**Яңа шәһәр,52/36,52 нче**
**татар гомуми белем**
**бирү мәктәбе**
**Телефон:59-36-88**
**Факс:(8552)**
**59-36-90**
**Эл.почта:**
**Sch52_ chelny@ mail.ru**
**Без Вебта:http://**
**Edu.tatar.ru/n_chtlny/**
**Sch52**